Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге Советы

**КАРАР №3**

Балыклы-Чүкәй авылы 2025 елның 7 феврале

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге Советының 2017 елның 4 сентябрендәге 11 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының 2022 елның 19 июлендәге 01-16/5057 номерлы хатын үтәү йөзеннән, юл сервисы объектлары урнашкан территорияләрне тотуга һәм җыештыруга контрольне тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге Советының 2017 елның 4 сентябрендәге 11 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә (15.11.2018 ел №16; 13.08.2019 ел № 11; 02.11.2020 ел № 5; 07.08.2024 ел №6 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.6.1.4. пунктын түбәндәге эчтәлектәге 9 нчы абзац белән тулыландырырга:

"Автомобиль юлларының юл буенда яисә алар тирәсендә урнашкан сервис объектлары (кибетләр, кафелар, кунакханәләр, АЗС (ягулык салу станцияләре), СТО (техник хезмәт күрсәтү станцияләре), ял мәйданчыклары һ. б.) өчен бүленгән территорияләрне карап тоту һәм җыештыру мондый объектларның хуҗасы (милекчесе) тарафыннан гамәлгә ашырыла.";

түбәндәге эчтәлектәге 4.13 нче бүлек белән тулыландырырга:

"4.13. Сервис объектларын тоту

4.13.1. Сервис объектлары территорияләрен карап тоту мондый объектларның хуҗасы (милекчесе) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.12.2. Юл буе сервисы объектлары территорияләрен төзекләндерү элементларының мәҗбүри исемлеге үз эченә алырга тиеш:

-уңайлы хәрәкәт итү өчен каты өслек;

-территорияне яктырту, архитектура-декоратив яктырту;

- аларны урнаштыру һәм карап тоту таләпләре үтәлгән бәдрәф кабиналары;

- чүп савытлары һәм кече контейнерлар;

- яшелләндерү (газоннар, чәчәклекләр) һәм яшелләндерү кишәрлекләрен саклау элементлары (киртәләр);

4.13.3. Сервис объектларын һәм аларга якын территорияләрне урнаштыруга һәм тотуга таләпләр үз эченә ала:

-сервис объектларына килү-китү, керү юллары күчеш-тизлек полосалары белән җиһазландырылырга тиеш;

-сервис объектларының күчеш-тизлек полосалары һәм территорияләре тышкы яктырту белән җиһазландырылырга тиеш;

- хәрәкәткә хезмәт күрсәтү корылмасы мәйданчыгына чыгу юллары юлдан су агызуның гамәлдәге системасына бәйләнгән буй су агызу юлы тәэмин ителерлек итеп төзелергә тиеш (чыгу юллары астына су үткәрү торбалары салынырга тиеш);

- хәрәкәткә хезмәт күрсәтү корылмасы мәйданчыгының һәм аңа таба чыгу юлларының буй авышлыгы юлның капма-каршы ягына юнәлдерелергә тиеш. Түгәрәкләнү радиуслары чикләрендә ул 20 % булырга тиеш;

- мәйданчык һәм аңа чыгу юллары автомобиль юлы белән бертигез тотрыклы камилләштерелгән катламга ия булырга тиеш;

- ГОСТ Р 52289-2019 таләпләре "Юл хәрәкәтен оештыруның техник чаралары. Юл билгеләрен, светофорларны, юл киртәләрен һәм юнәлеш бирүче җайланмаларны куллану кагыйдәләре” нигезендә юл хәрәкәтен оештыруның техник чаралары булу;

- сервис объекты территориясендәге җитешсезлекләрне эксплуатацияләү һәм тоту процессында бетерү ГОСТ Р 59292-2021 "Гомуми файдаланудагы автомобиль юллары. Җәйге тоту дәрәҗәсенә таләпләр. Бәяләү критерийлары һәм контроль методлары" һәм ГОСТ Р 59434-2021 гомуми файдаланудагы автомобиль юллары. Кышкы тоту дәрәҗәсенә таләпләр. Бәяләү критерийлары һәм контроль методлары” таләпләре нигезендә гамәлгә ашырылырга тиеш;

- функциональ билгеләнеш буенча хәрәкәткә хезмәт күрсәтү корылмасы территориясендә, шул исәптән, санитария-гигиена зонасы булырга тиеш;

- тышкы реклама һәм мәгълүматны урнаштыру чаралары техник яктан төзек һәм эстетик яктан каралган булырга һәм бирелгән техник шартларга туры китереп файдаланылырга тиеш;

- «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында»24.11.1995 ел №181-ФЗ Федераль законы нигезендә юл буе сервисы объектларында транспорт чараларын кую урыннарында инвалидлар идарә итә торган транспорт чараларын бушлай кую өчен урыннар бүлеп бирелергә тиеш.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында: Балыклы-Чүкәй авылы, Үзәк урам, 8 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының

хокукый мәгълүмат рәсми порталы’’нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Глава Балыклы-Чукаевского
сельского поселения
Рыбно-Слободского
муниципального района
Республики Татарстан — И.С.Мазитов